## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРМАНДЕЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

№ 59 01.02.2018 ел

**Урмандеевка авыл җирлеге башлыгының 2017 елда социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2018 елга фараз турында хисабы**

Урмандеево авыл җирлеге Советы башлыгының 2017 елгы социаль – икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2018 елга фараз турындагы хисабын тыңлап һәм фикер алышып. Авыл җирлеге советы 2017 елда авыл җирлеге халкы мәнфәгатьләрендә, «РФда җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясенең 6.10.2003 елдагы 131-ФЗ номерлы Законы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елдагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Урмандеево авыл җирлеге Советы карары:

1. Урмандеево авыл җирлеге башлыгы Николаев Валерий Зиновьевичның 2017 елда авыл җирлегенең социаль – икътисади үсеше нәтиҗәләре һәм 2018 елга фараз турында хисабын игътибарга алырга.

2. 2018 елда авыл җирлеген социаль – икътисади үстерүнең төп бурычы булып халыкның тормыш сыйфаты үсешен тәэмин итү санала. халыкның тормыш дәрәҗәсен төшерүгә һәм гражданнарның социаль хезмәтләргә тигез керү мөмкинлеген тәэмин итүгә юл куймау.

3. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә аерым игътибар бирергә.

4. Кредитлау һәм торак төзелеше өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган программаларның мөмкинлекләрен авылда яшьләрне ныгыту өчен максималь файдалану.

5. Хокук саклау органнары белән берлектә җәмәгать иминлеге дәрәҗәсен күтәрү һәм җәмәгать тәртибен, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген һәм дәрәҗәсен ышанычлырак яклауны тәэмин итү буенча алга таба эш алып барырга.

6. Торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча чараларны дәвам итәргә.

7. Авыл җирлеге башкарма комитетына хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә тәкъдим итәргә.

8. Авыл җирлеге Советы аппаратына хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерергә.

9. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http:aksubaevo.tatarstan.ru.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Урмандеевка авыл җирлеге Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Урмандеево авыл җирлеге

Советы Рәисе: В.З. Николаев